**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 октябрь № 780

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 143 нче, 2013 ел, 24 май, 348 нче, 2014 ел, 31 гыйнвар, 51 нче, 2014 ел, 11 август, 583 нче, 2015 ел, 18 май, 353 нче, 2015 ел, 5 сентябрь, 645 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 1 пунктындагы «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда бюджетлар керемнәре администраторы вәкаләтләрен башкару турында кабул ителгән хокукый актлар нигезендә бюджетлар керемнәре администраторы вәкаләтләрен башкаралар.»;

әлеге карарга кушымтаның II бүлегенә искәрмәдә «Татарстан Республикасы дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков